Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 6 (19)

1 март 2012 ел

## • Ике авыз сүз

24 февраль көнне КФУда РФ финанс министры, дөньяның алдынгы компанияләреннән белгечләр катнашында Планетарий төзү буенча җыелыш узды. Казан Планетариесенең эшче төркеме 9 илдәге 22 планетарий эшчәнлеге белән танышкан. Җыелышта «Планетарийнең гөмбәзе нинди булырга тиеш?» дигән төп сорауга җавап эзләнде. Бездә ике төрле – горизонталь яки вертикаль Планетарий төзелә ала. Ректор Илшат Гафуров фикеренчә, Планетарий дәүләт объекты түгел, ә университетныкы. Аның төп максаты: белем бирү процессында кулланылу һәм керем китерү.

• • • •

26 февраль КФУда Ачык ишекләр көне узды. Барлыгы РФ нең 12 субъектыннан 1200 ләп укучы катнашты. Алар игътибарына уку йорты эшчәнлеге, мәдәни чаралар, спорт тормышы турында мәгълүмат тәкъдим ителде. Чарага килгән укучылар үзләрен кызыксындырган сорауларга тулы җавап ала алды. Гомуми Ачык ишекләр көне янәдән 30 мартта узачак.

• • • •

27 февральдә ректоратның чираттагы утырышы үтте. Беренче булып ректор ТР Президенты Рөстәм Миннеханов визиты турында чыгыш ясады. Республика җитәкчесенең университет үсешеннән канәгать калуын әйтте. Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин Үсеш программасының барышы турында сөйләде.

Алга таба Филология һәм сәнгать институты директоры Р.Җамалетдинов чыгыш ясады. Институт тарихи традицияләрне һәм заман таләпләрен берләштереп эшли. Шулай ук киләчәккә планнар, ике яңа юнәлеш буенча ачылачак магистрлык программасы һәм докторантура турында мәгълүмат җиткерелде. Директор Кече филология һәм сәнгать институты ачуга бәйле планнары белән дә уртаклашты. Бирәдә 7-11 сыйныф укучылары белем алачак.

Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты эшчәнлеге турында директор Искәндәр Галиев чыгыш ясады. Ул шулай ук яңалыклар белән таныштырды: 3 яңа бакалавриат, 2 магистратура программасы һәм киләчәккә планнар турында сөйләде.

С.Ионенко кабул итү кампаниясе буенча хисап тотты. Ачык ишекләр көне һәм «Кабул итү волонтеры» хәрәкәте эшчәнлегенең беренче этап нәтиҗәләре белән таныштырды.

Ректоратның йомгаклау өлешендә уку-укыту эшләре буенча проректор Рияз Минзариповның КФУ ның Яр Чаллы филиалы халык хокукы кафедрасын конституцион, административ һәм халыкара хокук кафедрасы дип үзгәртү тәкъдимен кабул иттеләр. Утырышны йомгаклап, ректор институт директорлары һәм факультет деканнарына якын арада югары стипендиягә лаек студентлар исемлеген әзерләргә кушты. Алдынгы 900 студентка стипендия түләү өчен, елга 82 млн. сум акча бүлеп бирелә.

• • • •

28-29 февраль көннәрендә II Халыкара «Тормыш иминлеге куркынычсызлыгы проблемалары: теория һәм практика» фәннигамәли конференциясе узды. Бирәдә КФУ вәкилләре дә күп иде. Куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендә хезмәттәшлекне киңәйтү чараның төп максаты булып тора. Конференциядә РФ Хөкүмәте рәисенең беренче урынбасары И.Шувалов, РФ нең транспорт министры И.Левитин, эчке эшләр министры Р.Нургалиев, ТР Президенты Р.Миннеханов, Премьер-министр И.Халиков, гадәттән тыш хәлләр буенча министр Р.Хәбибуллин катнашты. «Корстон»да узган пленар утырыш вакытында Франция, Италия, Финляндиядән килгән алдынгы белгечләр куркынычсызлыкны тәэмин итү проблемаларын күтәрде.

• • • •

Алабугада «Дөнья буяулары» дип аталган Халыкара яшьләр фестивале уза. 18-24 март көннәрендә КФУ ның Алабуга филиалы һәм шәһәрнең бер кинотеатры белән берлектә бушка фильмнар күрсәтеләчәк. Тамашачылар өчен Россия, Европа һ.б. илләрнең 10 тулы һәм 30 кыскаметражлы кинолары тәкъдим ителәчәк. Шулай ук фестиваль вакытында мастер-класслар һәм «түгәрәк өстәлләр», иҗади очрашулар һәм махсус чаралар үткәреләчәк. Россиядә мондый фестиваль беренче тапкыр уздырыла һәм киләчәктә ел саен оештыру планлаштырыла.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*


Алия Галимуллина фотосы

## Рөстәм Миннеханов: «Көндәшлеккә сәләтле белгечләр булдырырга кирәк!»

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Кичә «Татнефть Арена» боз сараенда «Универсиадага кадәр 500 көн» уңаеннан Волонтерларның «Без әзер!» дип аталган I Бөтенроссия студентлар форумы узды.

Чарада РФ Хөкүмәте рәисенең беренче урынбасары И.Шувалов, РФнең Спорт, туризм һәм яшьләр сәясәте министры В.Мутко, ТР Президенты Р.Миннеханов, Казан Мэры Илсур Метшин, югары һәм урта махсус уку йортларыннан волонтер-студентлар, Универсиада дирекциясе партнерлары, шоу-бизнес йолдызлары, Россиянең һәм Татарстанның танылган спортчылары һ.б. катнашты. Волонтерлар арасында зур күпчелекне КФУ студентлары алып тора иде.

Форумның төп идеясе – Универсиаданы Россия яшьләренең милли проекты буларак кабул итү, «Казан – 2013» волонтерлык программасын популярлаштыру, вузара дуслыкны ныгыту.

Форумны ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, режиссер, актер Михаил Волконадский һәм танылган җырчы Юлия Ковальчук алып барды. Чара барышында РФнең 17 субъектыннан килгән волонтерлар парады булды. Шулай ук Россиянең иң эре университет үзәкләре – Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа, Түбән Новгород, Ижау, Красноярск, Владивосток – турыдан-туры элемтәгә керде. Казан волонтерларына Кытайның Шеньжэнь волонтерлары «Волонтерлар уты» факелын тапшырды.

Хәтерләсәгез, әле 25 февраль көнне ТР Президенты Рөстәм Миннеханов безнең университетта укытучылар, аспирантлар һәм студентлар белән очрашкан иде. Университетның кайбер лабораторияләрен күзәтеп чыкканнан соң, утырыш конференц-залда дәвам итте.

**Ахыры 2нче биттә.**


## • Казаныш

## Югары бәя

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Кичә Казан федераль университетында «Зур текст коллекцияләрендә бизнес-вакыйгалар турында мәгълүмат эзләү һәм алу» фәнни-тикшерену эше өчен тантаналы рәвештә сертификат тапшыру чарасы узды. Шулай ук студентларга HP компаниясе технологияләре турында лекция укылды.

КФУ ның ИТИС Югары мәктәбе «Интеллектуаль эзләү системалары һәм семантик технологияләр» лабораториясе конкурсның триумфаторы булып тора. Конкурста Россиянең бик күп югары уку йортлары катнаша. Ләкин «ХЬЮЛЕТТ-ПАККАРД А.О.» компаниясе КФУ ны сайлый.


Диана Поварова фотосы

КФУ ның ИТИС Югары мәктәбе «Интеллектуаль эзләү системалары һәм семантик технологияләр» лабораториясе узган елның декабреннән генә эшли башлады.

**Ахыры 3нче биттә.**

Рөстәм Миннеханов:

# «Көндәшлеккә сәләтле белгечләр булдырырга кирәк!»

**Башы 1нче биттә.**

Сәгать ярымлык очрашуда һәркем үзен борчыган сорауларны Президентыбызга җиткереп калырга тырышты. Сорауларның күпчелеге вуздагы проблемалар, аларның чишелеше турында булды. Рөстәм Миннеханов билгеләп үткәнчә, университетта үзгәрешләр бары яхшы якка таба гына бара. КФУ ның дәрәҗәсе һаман саен үсә, шуңа күрә әледән-әле яңа проектлар, программалар уйлап, аларны тормышка ашыру юлларын табарга кирәк. Дөрестән дә, университетыбызның дәрәҗәсе башка вузлардан шактый өстен. Беренчедән, студентларның тулай торак белән тәэмин ителеше 100% ны тәшкил итә. Бу исә Универсиада авылының нәкъ менә Казан федераль университеты карамагына тапшырылуы белән бәйле. Икенчедән, укытучыларның уртача хезмәт хакы 30 мең тәшкил итә.




Сергей Тябин фотосы

Университеттагы үзгәрешләр, яңалыклар белән ректор Илшат Гафуров таныштырды. Ул сөйләгәннәргә таянып, шуны әйтергә була: бүгенге көндә КФУда 581 торак объекты бар һәм аларның күпчелеге нәкъ менә шәһәр үзәгендә урнашкан. Һәр корылма үзенә тиешле игътибар, җиһаз, төзекләндерү таләп итә. Ә Президент Аппараты бу уңайдан бик зур ярдәм күрсәтә.

Хөкүмәт башлыгы барлык проблемаларны да хәл итеп булачак, дип белдерде һәм университетның бүгенге торышыннан канәгать булуын әйтте. Вузларда белем бирүнең сыйфатын да онытып җибәрмәскә кирәк. «Бүгенге көндә икешәр-өчәр вузда берьюлы укучылар бар. Аларның берсендә генә уку да зур көч һәм белем таләп итә, шунлыктан бер юнәлештә генә белем алу һәм ул укуны чит илдә дәвам иттерү мөмкинлеге булдырырга кирәк. Менә шул очракта бездә чыннан да дөнья базарында көндәшлеккә сәләтле белгечләр булачак», – дип билгеләп үтте Рөстәм Нургали улы.

Очрашуда эре предприятиеләр белән килешүләр төзергә кирәклеге турында да сүз булды. Чөнки эш таба алмаса, безнең студентлар чит төбәкләргә китеп барырга да күп уйлап тормаячак. Алар федераль вуз дипломы алып чыгалар бит!

Киңәшмә азагында Президент мондый очрашуларның бик әһәмиятле булуын әйтеп узды. Ул очрашуны: «Казан федераль университеты һаман үсештә һәм Татарстанда фән, белем бирү дәрәҗәсе һәрвакыт лидерлар рәтендә булырга тиеш!» – дигән оптимистик шигарь астында тәмамлады.

● Сайлаулар – 2012

# «Лидерга тавыш бирәчәкбез!»

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Татарстан һәм Россия күләмендә үзләренең гыйльми эшчәнлекләре белән танылган Казан Федераль университетының күренекле татар галимнәре, 4 март көнендә узачак сайлауга багышланган әңгәмәдә катнашып, илебездә үткәреләсе бу зур вакыйгага, хәзерге сәясәткә карата үз карашлары һәм фикерләре белән уртаклаштылар.



**Наил Мансур улы Вәлиев,** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты, Дәүләт советы депутаты, филология фәннәре докторы, профессор: «Әлбәттә, лидерга тавыш бирәчәкбез, ул бар инде безнең... Башка кандидатлар арасында сайларлык кеше күрмим».



**Фаяз Шәриф улы Хуҗин,** тарих фәннәре докторы, КФУның Тарих институты профессоры: «Сайлауларда Брежнев заманнарыннан бирле катнашып килгән өлкән кеше инде мин. Һөнәрем буенча тарихчы. Реформалар илендә яшибез. Сәясәтнең нәрсә икәнен һәм бертуктаусыз барган реформаларның нәрсәгә китергәнен аңлыйм.

Президент сайлауларына да санаулы көннәр калып бара. Кемне президент итәргә? Мин пропагандист та, агитатор да түгел. Шуны гына әйтә алам: Зюганов та, Жириновский да, миңа калса, сайлау кампаниясендә элеккедән калган гадәт буенча гына катнашалар. Алар үзләре дә президент булудан куркалар. Миллиардер Прохоров сәясәткә әле яңа гына кереп бара, ул әле сыналмаган. «Гадел Россия» лидеры Мироновның программасы кызык кына. Әмма шул матур программаны тормышка ашыру механизмы эшләнмәгән. Кала Путин. Унике ел хакимият башында, без аны беләбез. Ни генә сөйләмәсеннәр, халык әле һаман аңа ышанычын югалтмады. Мондый ышанычның нигезе дә юк түгел. Ул киләчәккә юнәлтелгән реаль программасын тормышка ашырырга сәләтле».



**Алмаз Мирзанур улы Галимов,** КФУның инновацион эшчәнлек буенча проректор урынбасары, педагогика фәннәре кандидаты, доцент: «Мөнәсәбәтләр үтә җитди. Быел сайлау процессы бик үзенчәлекле. Көчләрнең үзара бәрелеше генә дә ни тора! Сайлауга бару – һәр кешенең гражданлык бурычы».



**Фоат Галимулла улы Галимуллин,** КФУның Филология һәм сәнгать институты профессоры: «4 март – ил язмышы хәл ителә торган, кыл өстендә торган көнебез. Киләчәктә аның нинди булачагы, дөньяда нинди урын тотачагы да бу көн белән бәйле. Җаны булган кеше теләсә кемне түгел, ил язмышын хәл итәчәк бер генә кеше икәнлекне дөрес аңлап, үзенең киләчәге өчен дә бик мөһим, әһәмиятле сайлауга килмичә калмас».



**Альберт Әхмәтҗан улы Борһанов,** тарих фәннәре докторы, КФУның Тарих институты профессоры: «Былгы сайлаулар гадәттәгеләрдән үзенең активлыгы белән аерылып тора. Халык сукыр түгел, ул үзе ышанган, эшләп күрсәткән реаль, конкрет лидерны сайлаячак. Булачак президентның милли проблемаларны да уйлап эшләвен теләр идем».

● Эшлекле сөйләшү

# Тарихны - кыйпылчыклап

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче



Алия Галимуллина фотосы

28 февраль көнне КФУның Тарих институты, Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты галимнәре, Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институты белән берлектә, борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя утрау-шәһәрчеге археологик объектларын комплекслы өйрәнү буенча фәнни семинар үткәрде.

Әлеге семинар кысаларында физик, химик, биологик, палеоклиматик, геофизик ысулларның яңа нәтиҗәләре һәм археологик тикшеренүләрнең технологияләре мәсьәләсе яктыртылды. Чыгыш ясаучылар 2012-2014 елларга Болгар шәһәрен өйрәнүнең төп нигезләмәләре белән таныштырып, шуңа бәйле фикерләрен җиткерделәр, яңа проектлар белән уртаклаштылар. Семинарның төп бурычы – Россия һәм чит ил тикшеренүчеләрен җәлеп итеп, әлеге объектларның тарихи-мәдәни мирасын гомумиләштереп өйрәнү, архитектура һәйкәлләренең үз даирәсен булдыруда фәнни һәм мәгълүмати яктан комплекслы якын килү.

«Болгар шәһәрен һәм Зөя утрау-шәһәрчеген археологик тикшерүләр» дип аталган бу семинарда беренче мәсьәлә буларак Болгар шәһәрен өйрәнүнең торышы каралды. Әлеге тарихи өйрәнүләр инде 1864 елда Тизенгаузенның археологик эзләнүләре белән үк бәйле. Хәзерге вакытта берничә фәнни өйрәнү юнәлешләре эшләп килә. Болгар һәм әлеге шәһәр комплексына караган җирлекләрдә геомәгълүмати система барлыкка китерү; комплекслы археологик-архитектур һәм табигый-фәнни өйрәнүләрне тормышка ашыру; заманча төгәл кыр фиксациясе ысулларын кулланырга өйрәтү; яшәү тирәлеген һәм хуҗалыкларны кабаттан торгызу; борынгы җитештерү технологияләрен кабат тергезү һәм кулланышка кертү (керамика, тимер, таш эшкәртү һ.б.) әнә шундыйлардан.

Барчабызга мәгълүм тарихи урыннар инде күп кенә тарихчы-тикшеренүчеләрне үзенә тартса да, казу эшләре алып барылса да, әлеге көнгә кадәр археология һәм архив мәгълүматлары буенча билгеле булган, ләкин тикшерелмәгән тарихи объектлар бар. Елга буе вокзалы мунчасы, базар мәйданындагы мәчет, Арасимов утары янындагы биналар әле дә булса ахырга кадәр өйрәнелеп бетмәгән.

Семинарга килгән галим-тикшеренүчеләр «Болгар җирлегендәге хайван сөякләре калдыкларын зооархеологик тикшерү», «Болгар керамикасын өйрәнүнең якынча фәнара нәтиҗәләре», «Болгарда металл һәм тимер эшкәртү эшчәнлеге», «Болгар пыяласы. Археологик пыяланы өйрәнү ысуллары һәм проблемалары» кебек темаларга ике дистәгә якын доклад әзерләгән иде.

Катнашучыларның докладлары, чыгышларыннан күренгәнчә, музей-тыюлыкларны өйрәнү зур тизлек белән бара. Әлеге археологик тикшеренүләр кысаларында Болгарда зур мөмкинлекле фәнни программалар, тәҗрибә уртаклашу өчен, заманча археологик һәм фәнара тикшеренүләр фәнни-методик үзәге, яңа ысуллар һәм технологияләр булдыру, аларны куллanылышка кертү, Болгар музей-тыюлыгы кунаклары өчен заманча мәгълүмати һәм музей комплексы барлыкка китерү кебек нәтиҗәләр көтелә.

● ЖУРФАКТА КУНАКТА

БҮГЕНГЕ ЗАМАНДА ХӘТТА БЕР КӨН ДӘ МӘГЪЛҮМАТСЫЗ ЯШӘП БУЛМЫЙ. МӘГЪЛҮМАТНЫ ТУЛЫ ҺӘМ АҢЛАЕШЛЫ ИТЕП ҖИТКЕРҮ ӨЧЕН, ЖУРНАЛИСТЛАРНЫҢ НИЧЕК ТЫРЫШКАНЫН АҢЛАТЫП ТА БУЛМЫЙ ХӘТТА. ӘЛЕГЕ ӨЛКӘ БУЕНЧА ТАТАРСТАНДА ЮГАРЫ БЕЛЕМЛЕ БЕЛГЕЧЛӘР ӘЗЕРЛИ ТОРГАН БЕРДӘНБЕР ҮЗӘК – ЖУРНАЛИСТИКА ҺӘМ СОЦИОЛОГИЯ ФАКУЛЬТЕТЫ. ФАКУЛЬТЕТ УКЫТУЧЫЛАРЫ ЯР ЧАЛЛЫ ФИЛИАЛЫНДА ДА ДӘРЕСЛӘР АЛЫП БАРА.

# Журналистлар - үз өйләрендә!

Динара ӘХМӘТОВА,
хәбәрче



**Журналистика бүлегеи тәмамлаган студентларның 75-80% үз белгечлеге буенча эшкә урнаша. Алга таба факультетны нинди үзгәрешләр көтә? Аның бүгенгесе һәм үткәне турында без факультет деканы, филология фәннәре докторы Васил Заһит улы Гарифуллин белән әңгәмә кордык.**

***– Васил абый, бу семестрны яңа урында башлап җибәрдегез. Кәефләрегез ничек?***

– Аллага шөкер, бар да яхшы. Бүген, гомумән, берникадәр яңа шартларда эшлибез инде. КФУ салган юнәлеш буенча үзебезнең үсеш программасын булдырдык. Аны тормышка ашыру өчен, безгә аерым бина да бирделәр. Ул өч катлы, бик зур, үз өебез булуы студентларга да ошый, чөнки төрле биналар буенча йөгереп йөрисе юк.

***– Бу яңа мөмкинлекләргә юл ача, минемчә?***

– Әлбәттә, бу җиһазланыш өчен бик яхшы. Университет телеүзәге белән бергә монда өйрәнчек телевизион студия урнаштырабыз. Иң алдынгы студияләрдә генә эшли торган җиһазларны Мәскәү белгечләре куячак. Материалны эшкәртү, ягъни монтажлау аппаратлары да булачак. Фотожурналистика студиясен җиһазландыра башладык. Компьютер класслары ачтык. Шулай ук өйрәнчек газета редакциясе бар. Кече курс студентлары, тәрҗемәнәргә берләшеп, семестрга бер тапкыр үзләренең газетасын чыгара.

***– Әлеге яңалыклар факультетның традицияләре юкка чыгуга китермәсме соң?***

– Безнең максат аларны саклап калу инде. Редакцияләр каршында уза торган җәйге практикалар кала. Атнага бер бирелә торган традицион иҗат көнендә студентлар, билгеле бер редакциягә беркетелеп, практикага йөриләр һәм семестр саен хисап тапшыралар. Аннан соң бездә «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире Миңназыйм Сәфәров, «Татарстан-Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясенең генераль директоры Илшат Әминов, аның урынбасары Миләүшә Айтуганова, шулай ук Римзил Вәлиев, Ислам Әхмәтҗанов, Мәгъсүм Гәрәев кебек таныклган журналистлар фән серләренә өйрәтә. Студентларыбызның күбесе журналист булып эшли. Иҗат белән теорияне бәйләү бик авыр һәм укуга зыян сала. Безнең бик яхшы укый торган студентларыбыз бар, ләкин кайберләренең иҗатка сәләте юк. Ә яхшы яза торган студентларыбызны дәрескә йөрмәү аркасында укудан куган очраклар да булды. Алар белем алуның кирәклеген аңлап, яңадан кайтып, читтән торып булса да укып бетерделәр.

***– Еш кына махсус өлкә буенча журналистлар җитми, дигән моң-зарларны ишетергә туры килә. Бигрәк тә бу спортка бәйләп аңлатыла. Факультетта әлеге мәсьәләне чишү өчен, нинди чаралар күрелә?***

– Бу – бәхәсле проблема. Без махсуслашуны массакүләм мәгълүмат чаралары буенча үткәрергә тырышабыз. Төркемдә, ким дигәндә, 8 кеше булырга тиеш, ә бюджетка 10 кеше алабыз. Тематик махсуслашу турында сүз дә була алмый. Безнең белгечләр дә бар, ләкин мөмкинлекләр чикле. Әлбәттә, Университетада алдыннан журналистлар өчен махсус мастер-класслар, очрашулар уздырылачак. Без алдагы елларда да шулай эшли идек.

***– Әңгәмәгез өчен бик зур рәхмәт. Уңышлар телибез Сезгә!***

● ТӘҮГЕ АДЫМНАР

# Ирләргә хас кыюлык

Регина РАЯНОВА,
татар филологиясе бүлеге студенты

БЕЗ БЫЕЛ ТӘҮГЕ ТАПКЫР ПРАКТИКА ҮТТЕК. КАЗАН ШӘҺӘРЕ КИРОВ РАЙОНЫНЫҢ 15 НЧЕ ТАТАР ГИМНАЗИЯСЕНДӘ ИКЕ АЙ УКУЧЫЛАР БЕЛӘН ЭШЛӘДЕК. ТӨРЛЕ ЧАРАЛАР, КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР ДА ҮТТЕ. ШУНДЫЙЛАРНЫҢ БЕРСЕ ТУГАН ТЕЛ КӨНЕ УҢАЕННАН ШАГЫЙРӘ, ЖУРНАЛИСТ, ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ НӘҖИБӘ САФИНА БЕЛӘН ОЕШТЫРЫЛДЫ.



Кызганычка каршы, без туган тел, сүз кадере беткән заманда яшибез. Бу вакытта Туган тел көне кебек бәйрәмнәр дә бик мөһим. Укучылар шагыйрәнең иҗат җимешләре, шигырьләре, белән таныштырып үтте. Күбрәк туган телебез – татар теленә, халкына һәм татар халкының гореф-гадәтләренә багышлап язылган шигырьләр яңгырады. Укучыларның нәкъ әлеге шигырьләрне сайлавын Нәҗибә Сафина үзе дә хуплады. «Әгәр миңа чыгыш ясарга кушсалар, мин дә нәкъ шушыларын сайлап алган булыр идем», – дип шаяртып та алды ул.

Алга таба сүз шагыйрәнең үзенә бирелде. Ул безгә үзе турында гына сөйләп калмады, тел мәсьәләсенең бүгенге хәле һәм аны чишү юллары турында да сүз алып барды. Сөйләгәннәрен иҗатыннан һәм тормышыннан мисаллар китереп дәлилләде. Шагыйрә, мәктәптә эшләгән кеше буларак һәм тамашачыларның яшь үзенчәлекләрен истә тотып, «ял минутлары» да оештырды, ягъни курайсыз гына курайда «уйнап күрсәтте», сорауларына дөрес җавап биргән укучыларга китаплары бүләк итте.

Нәҗибә Сафина заманында Казан университетында укыды һәм, иң мөһиме, минем якташым булуы белән күңеләмә якын. Кичә барышында мин аңа карап, сокланып һәм горурланып утырдым. Ә ул иҗат иткән әсәрләр, бигрәк тә балалар өчен язылганнары үзе бер сихри дөнья дип әйтер идем мин.

Кайчандыр гади студент кына булган, бүген инде талантлы шагыйрә, үткен сүзле журналист булып танылган, үзенең иҗаты белән күпләрне сокландырган Н.Сафина иҗатын югары бәяләп, остазы Марсель Бакиров юкка гына мондый сүзләр әйтмәгән икән: «Шагыйрь булу өчен ихласлык һәм талант кирәк. Ә бу сыйфатлар Нәҗибәдә бар. Анда ирләргә хас кыюлык та көчле. Ул кеше йөргән сукмактан йөрми. Аның үз сукмагы, үз тавышы бар. Тирән фәлсәфә дә, моң да җитәрлек. Ул шигырьләре белән һәркем күңеленә ачкыч таба белә. Нәҗибәнең йөрәге халык язмышы, туган телебез язмышы өчен борчыла, тетрәнә. Аның иҗаты югары бәяләнергә бик хаклы».

Туган телгә багышланган әлеге чарада сүз телгә, сүзгә карата, гамьсезлектән арыну хакында барды. Әлеге залда утыручылар шул хакта уйланырга мәҗбүр булганнардыр...

● ӨЙРӘТӘЛӘР МӘКТӘПЛӘРДӘ

# Көчле алмаш килә

Сиринә ТРОФИМОВА,
хәбәрче

28 ФЕВРАЛЬ КӨНЕН САРМАН РАЙОНЫ ҖӘЛИЛ БИСТӘСЕНЕҢ 2 НЧЕ ГОМУМБЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫ ҺӘМ УКЫТУЧЫЛАР КОЛЛЕКТИВЫ ДУЛКЫНЛАНЫП ҺӘМ ШАТЛАНЫП КӨТЕП АЛДЫ. ИНДЕ ИКЕНЧЕ ЕЛ РӘТТӘН АЛАР РЕСПУБЛИКА КҮЛӘМЕНДӘ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯ УЗДЫРАЛАР.



Быелгысы – герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 106 ел тулуга багышланган иде. Чакырылган кунаклар арасында Казан федераль университеты галимнәре, КФУның Төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең белемен камилләштерү һәм яңадан әзерләү үзәге, Әлмәт дәүләт нефть институты, Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институты укытучылары, галимнәре дә катнашуы бу чараның ни дәрәҗәдә җитди булуы турында сөйли.

Пленар утырыштан соң 14 районнан килгән укучылар, 5 төркемгә бүленеп, секция эшләрендә катнашты. 8-11 сыйныф укучылары туган як әдәбияты, сәнгате, күренекле кешеләре, туган якны өйрәнү һ.б. шундый темаларга карата эшләнгән фәнни хезмәтләрен яклады. Жюри әгъзаларын таң калдырган эшләр байтак булды. Мисал өчен «Туган якны өйрәнү» секциясендә катнашкан 24 укучы арасыннан фәнни хезмәте I урынга лаек булган Сарман районы Җәлил гимназиясенең 9 сыйныф укучысы Чулпан Галиеваның «Җырлы Сарман төбәгендәге табигый һәйкәлләр һәм аларның якташ әдипләребез иҗатында чагылышы», II урынны яулаган Яр Чаллы шәһәре 2 нче гимназиясенең 10 сыйныф укучысы Ләйсән Шакированың «Раян Зәбиров – җәлилче», III урын призеры – Актаныш районы 1 нче урта гомумбелем бирү мәктәбенең 11 сыйныф укучысы Инзилә Шәйхразиеваның «Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты «Агыйдел» халык җыр һәм бию ансамбле тарихыннан» дип аталган эшләре фәнни югарылыктагы хезмәтләр дип билгеләнде. Башка секцияләрдә катнашкан 25-30 лап укучы арасында да беренче өчлеккә керүчеләрнең эшләре кызыклы да, заманча да, фәнни дә иде. Галимнәрне көчле алмаш килүе бик сөендерде.

# Югары бәя

Башы 1нче биттә.

Бүлекнең төп юнәлешләре булып фәнни тикшеренүләр һәм мәгълүмати технологияләр өлкәсендә гамәли эшләнмәләр җитештерү, алдынгы үзәкләр белән хезмәттәшлек итү тора.

HP – дөньяның 170 илендә югары технологияләр белән эшли торган иң эре компания. Алар технология өлкәсендә килеп туган проблемаларны чишәргә, яңа нәтиҗәләргә ирешергә, ихтыяҗ һәм максатларны тормышка ашырырга ярдәм итә. Калган компанияләр HP кебек киң ассортиментлы технологик чишелешләр тәкъдим итә алмый.

Компаниянең Казан университетындагы үзәге 2009 елда оеша. Лаборатория җитәкчесе, КФУ профессоры Валерий Соловьев сүзләренә караганда, HP хезмәткәрләре КФУның фәнни-тикшеренү лабораторияләрен югары бәяләгән. Шул уңайдан, компания җитәкчелеге Валерий Соловьевка 30 мең доллар күләмендә сертификат тапшырды. Әйтергә кирәк, әлеге компаниядән фәнни тикшеренүгә заказны КФУ беренче тапкыр кабул итә. Алга таба хезмәттәшлек дәвам итәчәк һәм яңа проектлар тормышка ашырылачак.

● Алар бездә укыган

# «Халкымның киләчәге өчен борчылам!»

**Руслан ХӨСНЕТДИНОВ,**
махсус хәбәрче

Мәдинә Маликова белән аларның өйләрендә очраштык. Ерактан гына күреп белсәм дә, Мәдинә апаны бик ачык кеше дип уйлый идем. Язучы белән әңгәмә корганнан соң, аның әчкерсез, гади кеше икәненә инандым. Башка язучылар, артистлар кебек сорауларга сайланып түгел, тәгәл, тулы итеп җавап бирде, үзе пешергән тәмле ризыклар белән сыйларга да өлгерде. Җанлы әңгәмәбез дә нәкъ менә табын янында башланып китте.



**– Мәдинә апа, узган елга нинди нәтиҗәләр чыгара аласыз?**

– Мин хәзер үземә алай артык күп бурычлар куймыйм. Дөньяның рәхәтен, тормышның тәмен тоеп, үземне оҗмахтагы кебек хис итәм. Чөнки мин авыр елларны, бигрәк тә ачлык елларын үз күзләрем белән күреп үскән кеше. Хәзер матур дөньяда яшибез дип саныйм. Узган елга килгәндә, бу елны чагыштырмача уңышлы үтте дип уйлыйм. Җәй көннәрендә иҗат итүдән туктап торып, бераз ял иттем. Ямьле җәй айлары Казансу елгасы янында урнашкан бакчамда үтте. Ай ярым су коендым, ял иттем. Язылачак әсәрем өчен хисләр туплады. Табигатьнең матурлыгын күреп, аны күңелемә сеңдереп калдым. Көннәр салкынга авышкач, яңа романым өстендә эшли башладым, аның каралмасы әзер инде. Бу әсәремне тәмамлаганнан соң, детектив әсәр өстендә эшлиячәкмен.




**– Сезгә язучы буларак танылу өчен, озак вакыт кирәк булдымы?**

– Мин институтта укыган вакытта, газеталар белән языша башладым. Сәләтемне күрделәр, бәяләделәр һәм, укып бетергәннән соң, эшкә калырга тәкъдим иттеләр. Үземне чын язучы буларак бик иртә хис иттем. «Казан каласы – таш кала» повесте басылып чыкканнан соң, югары бәяләделәр. Тагын да канатланып иҗат итә башладым. Аннары әсәрләремне мөхәррирләр артык төзәтмәде, алайса кайбер язучыларныкын кызартып-кызартып төзәтеп бетерәләр иде.

**– Шактый гомер кичергән кеше буларак, Сездән сорыйм әле: яшәү мәгънәсе нәрсәдә дип уйлыйсыз?**

– Минемчә, кешенең яшәү мәгънәсе – яхшылыкка хезмәт итүдә. Ипи пешергән, юллар салган кешеләрне бик хөрмәт итәм мин. Аларны һаман саен яхшылык эшлиләр дип саныйм. Төрле ачышлар ясаган, әйберләр уйлап тапкан кешеләргә сокланып карыйм.

**– Китап чыгарып кына язучыга яшәргә акча җитәме?**

– Әлбәттә, җитә. Кайчагында чит илгә ял итәргә барып кайтырга да кала.

**– Сез өч ел рәттән Тукай премиясенә дәгъва кылучылар исемлегендә булдыгыз. Бу премияне ала алмаганга, җаныгыз әрнемәдеме?**

– Мин Тукай премиясен ала алмадым, әмма юбилеем алдыннан Президент миңа фатирга ремонт ясарга акча бирде. Ремонтка бирелгән акчаны алгач, Тукай премиясен алгандай булдым.


**– Язучының бик күп вакыты өстәл янында уза. Хатын-кыз язучыга тәмле ризыклар пешерергә, өйләр җыештырырга вакыт каламы?**

– Язу эше бик күп вакытны ала дип санамыйм мин. Көненә 2-3 сәгать эшләсәң, бик житкән. Ашарга пешерергә, өйләр җыештырырга, керләр юарга – һәммәсен эшләргә дә вакытым кала.

**– Мәдинә апа, күңелегезне тырнап торган нинди проблемаларыгыз бар?**

– Мине иң борчыган мәсьәлә – татар халкының язмышы, киләчәге. Элеккеге еллар, тоталитар режим кайта күрмәсен дип тә борчылам. Шәхсән үземә килгәндә, бүген ничек яшим, гел шулай булып калсын, татар китапларын укучылар кимемәсен, артсын иде.

● Дөнья үзебезнеке



**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

# Модадан калышмыйбыз



*Әле кыш суыклары үтеп бетмәсә дә, мода артыннан калышмаучылар өчен инде кибет киштәләрендә төрле формадагы язгы-җәйге трендлар пәйда була башлады. Барлык чуар киемнәр арасыннан кайсын сайлап алырга? Быел ничек киенсәң, синең стилең иң заманчасы булачак соң?*

*Быелгы язгы модага ретро стиль үтеп керә. Икенче төрле әйткәндә, нәфислек алгы планга чыгачак. Озын күлмәкләр, плащлар, артык тәнгә сыланып тормаган блузкалар, киң балаклы чалбарлар — болар һәммәсе яңадан әйләнеп кайтачак. Ә инде төсләргә килгәндә, саргылт, алтынсу, шәфталу төсе, алсу һәм зәңгәрсу төсләр бик актуаль булыр дип көтелә. Әгәр дә инде син «мини»ларыңны озынрак, «очып тора торган» итәк-сарафаннарга алыштырсаң, һич кенә дә ялгышмаячаксың! Шулай итеп, быелгы сезонда ачык, тыныч, романтик стильдәге киемнәр игътибар үзәгендә булачак! Модадан калышмаска теләсәң, безнең киңәшләргә дә колак сал!*

● Сәламәтлек

# Кышкы бер көн

**Гөлинә ГАЙНУЛЛИНА,**
Механика һәм математика институты студенты

Әле кайчан гына елгаларга боз каткан, җиргә беренче кар яткан, тәрәзәгә бизәкләр ясап, кыш җиһанны биләп алырга җыенган чак иде. Инде менә кышның соңгы ае белән хушлаштык. Әлеге уйлар белән йөреп, иптәш кызыма февраль башларында шундый тәкъдим ясадым: «Әйдә, бу атнаны авылга кайткач, чаңгыда чыгып керәбез. Бер ял булыр, йөзләребезгә алсулык йөгерер, тәнебезгә сихәт алырбыз». Минем бу тәкъдимемә ул бер дә каршы килмәде, киресенчә, бик теләп ризалашты.



Их, көне дә көне. Сайлап куелса да, мондый көн туры килмәс, валлаһи. Болай булгач, чаңгыда чыкмый калу һич тә ярамас. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, чаңгыга бер-ике тапкыр баскан булды, тик анысы да узган ел.

Уйлашабыз: тигез җирдән генә шуаргамы, әллә таулырак җир сайлыйкмы?! Мин дә, иптәш кызым да күңеллелек яратабыз, шуңа да таулырак җирне сайларга булдык. Шуа торган җиребез текә түгел, курыкмыйча шуарга була. Әйе, минем моның кадәр рәхәтлек тойганым юк иде. Таяклар белән акрын гына этенеп җибәргәннән соң, чаңгылар йөгәнсез ат кебек, чиксезлеккә таба юл алгандай, алга ыргылалар. Шул чак синең битеңне салмак кына искән җилләр иркәләп кала, мондый рәхәтлектән тәнең буйлап ниндидер бер дулкын йөгереп уза. Юк, ул вакыттагы рәхәтлекне барыбер аңлатып бетереп булмый!

Өйгә кайткач та яңа узып киткән бер-ике сәгать гомерем турында башымда уйлар бөтереште. Чаңгыда чыгу, беренчедән, рәхәтләнеп ял итәргә мөмкинлек бирә, икенчедән, сәламәтлегебезгә дә файдасы зур. Мәктәп елларында чаңгыда шуган чаклар искә төште. Әле укытучы безгә чаңгыда шуу төрләрен дә өйрәткән иде: классик һәм тимераяктагы сыман шуу була икән. Шуа торган чаңгың үзеңнең буеңнан уртача 15-20 сантиметрга озынрак булырга тиеш. Шулай ук, шуганда, таякларның озынлыгы да бик мөһим. Чаңгы таягы үз буеңнан 20 сантиметрга кечерәк булса, шуу авырлык тудырмас. Ә киемнең уңайлы һәм җылысын сайларга кирәк. Болар бар да мәктәптә укытучының, чаңгы сайлап, шуарга чыгар алдыннан әйтелгән сүзләре. Чыннан да, чаңгыга басар алдыннан боларны белү һич тә зыян итмәс, минемчә.

Ышанам: күбегез кышны чаңгыларга басып озаткандыр. Әле салкынча кышкы һава тора. Кемнәрдер чаңгыда шууын туктатмый. Озакламый назлы язлар, җылы җәйләр, алтын көзләр. Ни генә булмасын, чаңгылар белән хушлашып торырга туры килер. Шулай да сәламәтлегебез турында онытмыйк!

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 999

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: ksu.ru

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.
Газета бушлай таратыла